Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№9 (139)

28 май 2015 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

Казан федераль университетының радиофизика кафедрасында **АРКАДИЙ КАРПОВ** җитәкчелегендә электрон мәгълүматны саклау буенча үзенчәлекле тикшеренү эше уздырылды. Галимнәр мобиль җайланмаларда шифрлы ачкычлар саклана торган микрочиплар булдырырга тели. Әлеге микрочиплар радиодулкыннарны кире чагылдырырга сәләтле булыр дип көтелә. Шуның нәтиҗәсендә, һәр мобиль җайланмадагы шәхси шифр һәм мәгълүматлар чит-ятларга билгеле булмаячак.

• • • •

КФУ вәкилләре 25-26 нчы майда Каһирәдә уздырылган **«РОССИЯ – МИСЫР САТУ-АЛУ ҺӘМ ҖИТЕШТЕРҮ ДИАЛОГЫ»** дип исемләнгән бизнес-форумда катнашты. Вәкиллекне КФУның инновацион эшчәнлек буенча проректоры **АНДРЕЙ АРТЕМЬЕВ** җитәкләде. Казан университеты казанышлары «Россия һәм Мисыр арасында медицина техникасы һәм фармацевтика өлкәсендә уртак эшчәнлекне арттыруның мөмкинлекләре» түгәрәк өстәле барышында тәкъдим ителде. Моннан тыш, А.Артемьев Каһирә университеты, Александрия судно төзелеше заводы һәм Мисырның фармацевтика компания вәкилләре белән күреште. Әлеге очрашуларда Россия-Мисыр мөнәсәбәтләренә ачыклык кертелде, КФУның нефтехимия, судно төзелеше, фармацевтика һәм IT-технологияләр өлкәсендә эшчәнлек алып барачаклыгы билгеләнде.

• • • •

25 нче майда ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** КФУ лицейларында белем алучы **УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Очрашу барышында КФУның киләчәге сәләтле, яңа үрләргә омтылучы студентлар кулында булуы ассызыкланды. Ректор, олимпиада-бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулаган укучыларга, КФУга укырга кергәндә өстәмә баллар туплау мөмкинлеген дә искәртте.

• • • •

22-23 нче майда КФУның **«КАР ДЕСАНТЫ»** төркеме үзенең **45 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕН УЗДЫРДЫ**. Бәйрәм Казан университетының Тарих музеенда узды. Икенче көнне десантлылар Мәңгелек утка чәчәкләр салу тантанасында булдылар.

• • • •

**КФУның IT-ЛИЦЕЙ УКУЧЫЛАРЫ** «Infomatrix» IT проектлар бәйгесендә **КӨМЕШ** һәм **БРОНЗА МЕДАЛЬ ИЯЛӘРЕ БУЛДЫЛАР**. «Infomatrix» ярышы Румыниянең мәгариф министрлыгы һәм «ISMB» төркеме ярдәме белән оештырыла. Быел ярышта **Алексей Кожарин**, **Тимур Шәфигуллин** һәм **Данияр Садыйков** чыгыш ясады. Алар лицей лабораторияләрендә эшләнгән яңа төр техника белән таныштырдылар. Жюри казанлыларның үзенчәлекле идеяләрен, аларны чынга ашыру юлларын югары бәяләделәр һәм киләчәктә дә сайланган юлдан тайпылмауларын теләп калдылар.

• • • •

Яз көне башкалабызда автомобильләр өчен **ТҮЛӘҮЛЕ ПАРКОВКАЛАР** барлыкка килде. Әлеге паркоматлар үзәк урамнарны машина күплегеннән азат итәр дип көтелә. КФУ территориясендә дә мондый җайланмаларны күрергә мөмкин. «Казанский университет» газетасы уздырган сораштыру нәтиҗәсе буенча, күпчелек хезмәткәрләр һәм студентлар паркоматлардан файдалануны уңайсыз дип тапты. Тулырак мәгълүматны КФУ сайтыннан табарга мөмкин.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*



# Студентлар Геннадий Зюганов белән очрашты

**КФУның актлар залында РФ Коммунистлар партиясе Үзәк комитеты рәисе, Дәүләт Думасында коммунистлар фракциясе лидеры Геннадий Зюганов белән очрашу узды.**

Әлеге чарада Россия коммунистларының лидеры студентларга һәм укытучыларга «Россия яңа каршылыклар алдында» дигән лекциясен тәкъдим итте. «Нинди генә авыр һәм катлаулы шартларда яшәргә туры килсә дә, тырышып эшләү һәм илнең абруен арттыру мөһим. Моның өчен ачык һәм гадел эшләргә кирәк», – дип белдерде. Шулай ук ул чыгышында тормышның күп өлкәләренә карата үз фикерләрен әйтеп үтте: «Кризис, сугышлар, Россиянең чит илләр белән мөнәсәбәте, икътисад – болар барысы да тәртипкә салынырга тиеш һәм моның өчен барыбыз да көчебезне куярга бурычлы».

Сәгать ярымлык очрашуда һәркем үзен кызыксындырган сорауларны да биреп калырга омтылды. «Студентлар, илнең тормышын яхшырту өчен, нәрсә эшли ала?» – дигән сорауга Зюганов: «Россиянең дәрәҗәсе һаман саен үссен өчен, әледән-әле яңа проектлар, программалар уйлап, аларны тормышка ашырырга омтылырга кирәк», – диде. «Һәм, әлбәттә инде, үзегезнең сәламәтлегегез турында онытмагыз, ихлас хезмәт итегез, киләчәктә дөрес тормыш иптәше сайлагыз», – дип тә өстәп куйды.

Чыгышы азагында Геннадий Зюганов мондый очрашуларның бик әһәмиятле икәнен әйтеп узды һәм үз партиясенең алтын медален университетка истәлекле бүләк итеп тапшырды. КФУ вәкилләре Коммунистлар партиясе лидерына Ленин сурәте төшерелгән картина бүләк иттеләр.



Матбугат үзәге фотолары



Кайтаваз

# Дөнья төсләре – бер сәхнәдә

**Ләйсән САБИРОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Эх, шушы ялкаулык аркасында күпме кызыклы вакыйгалар безнең катнашсыз үтеп китә. «Әй, иренәм мин анда барырга», – дибез дә, борылып ятабыз. Битарафлык гөнаһ бит ул, аеруча журналист өчен. Казан федераль университетында укучы чит ил студентларының гала-концерты була дигән игъланны ишеткәч, бик иренеп, ялкаулыгым аша атлап кына барган идем, хәзер сөенәм шуңа.



Влад Михневский фотосы

«Colours of the world at KFU» – «Цвета мира в КФУ» халыклар дуслыгы фестивале безнең университетта һәр елны үткәрелә. Мондый чара, һичшиксез, кирәктер, чөнки КФУда ике меңләп чит ил студенты белем ала. Бу сан буенча университет Россиядә беренче урыннарның берсен алып тора. Бу хакта КФУның тышкы мөнәсәбәтләр буенча проректоры **Линар Латыйпов** бәян итте.

Әйтергә кирәк, уку йортындагы башка илләрдән килгән студентларның тормышы бер концерт белән генә чикләнми. Моңа кадәр чит ил студентлары атналыгы кысаларында алар төрле спорт төрләрендә көч сынаштылар. Гала-концертта җиңүче спортчылар һәм командаларга бүләкләнде, аларга медальләр тапшырылды.

Концерт үзе чын мәгънәсендә төрле төсләре белән тамашачыны әсир итте, таң калдырды. Аның сюжеты алты тапкыр кул кысу теориясенә нигезләнгән иде. Шул теория ярдәмендә рус егете Данил үзенең мәхәббәтен эзләп тапты. Сәхнәдә Куба, Малайзия, Әзербәйҗан, Таҗикстан, Кытай, Африка һәм башка илләрдән килгән КФУ студентлары чыгыш ясады. Хәер, алар ул көнне гади студентлар түгел, ә чын артистлар иде. Аеруча, дүрт илдән килгән дүрт кызның бер шигырьне дүрт телдә сөйләүләре истә калды. Мин бер сүзен дә аңламадым, шулай да, бу шигырьнең мәхәббәт турында икәнен аңлар өчен, әллә нәрсә кирәк тә түгел иде инде. Соңыннан шул ук шигырьне рус телендә сөйләделәр үзе. Ялгышмаганмын: бу шигырь нәкъ менә мәхәббәт турында булып чыкты. Ни дисәң дә, бу саф хисләр бер милләт кешесен дә читләтеп үтми шул. Шулай ук Таҗикстан егетенең һәм Африка кызының матур тавышы күңелгә ятты, Кытай кызларының биюләре ошады. Үзебезнең татар һәм рус җыр-биюләрен генә күреп булмады концертта. Ярар инде, нишләтәсең, чит ил студентлары барыбер безнең илне, аның халкын, мәдәниятебезне яраталар. Яратмасалар, безгә укырга килмәсләр иде, шулай бит?

Концерттан соң кайбер студентлар белән фикер алыштым.

«Сезнең илдә ошый миңа, – дип башлады сүзен Таҗикстаннан килгән дүртенче курс студенты, булачак финансист Камилоджан Ашрапов. – Иң элек югары белем алырга Кытайга китмәкче идем, ләкин Россияне кулайрак күрдем. Һәм мин моңа үкенмим. Укуны тәмамлагач, магистратурага керергә уйлап торам».

Аннары Ирак студенты Әсхәр Аль Кураиши белән сөйләштем. «Казанны бик яратам, – диде Әсхәр. – Сездә тыныч, кешеләр дә әйбәт, якты йөзле. Әгәр бездә тынычлык гомумән юк. Сугыш бер көнгә дә тынып тормый. Хәзер кем кем белән һәм ни өчен сугышканны үзебез дә аңлап бетермибез инде».

Әсхәр белән сөйләшкәндә, янәшәдә тыңлап торган дуслары үзләренекен өстәде тагын. «Татарстанда кызлар матур», – диләр. Мальтазар исемлесе Казанда үз мәхәббәтен эзләп табуын һәм шул кызга өйләнәчәген дә белдерде.

«Ә татар ашлары ошыймы?» – дим. «Тәмлелеккә тәмле дә, ләкин безнең гарәп пылауына җитми инде», – диделәр. Әсхәр үзе теш табибы һөнәре буенча беренче курста укый. Укырга кергәнче, ул, башка чит ил студентлары кебек үк, бер ел дәвамында рус телен өйрәнгән. «Аралашырга авыррак булса да, әкренләп өйрәнеп киләм инде», – диде Әсхәр.

Иракълылар белән сөйләшкәннән соң, башыма җитди уйлар килде. Ә без үз илебездәге тынычлыкның кадерен беләбезме соң?

Африканың Конго демократик республикасыннан килгән Адәм Йимбей да, алдарак үз фикерләре белән уртаклашкан студентларга кушылып, Россиягә мәхәббәтен белдерде. Безнең илдә нинди кыенлыкларга очраву турында сораштырдым. Кыш көне генә бераз суыграк, ә калганнары бар да тәртиптә. Башка африкалылар белән бер-беребезгә терәк-таяныч булып яшибез», – диде Адәм.

Менә шулай, иренеп яткан җиремнән торып чыгып китеп, күпме хис-кичерешләр алып, яңа танышлар табып, илһамланып кайттым мин.

# Төшенкелеккә бирелүдән сак булыйк

**Фәнзилә МОСТАФИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Яз – уяну чоры. Ниндидер яңалыкка, үзгәрешкә омтылу фасылы. Мәхәббәткә сусаган җан һәм тәннең гыйшык хисләре белән сугарылу вакыты. Ни өчен нәкъ менә язын гашыйк булабыз соң? Җавапсыз мәхәббәт буламы? Һәм ни өчен күпчелек яшьләр, җавапсыз хисләрдән чыгу юлы буларак, үз-үзенә кул салуга кадәр барып җитә? Бу сорауларга җавапны Психология һәм белем бирү институтының гомуми һәм практик психология кафедрасы өлкән укытучысы, гештальт-терапевт Резеда Равил кызы Попова белән бергәләп эзләдек.

**– Резеда Равилевна, ни өчен без кубесенчә язын гашыйк булабыз? Моңа берәр нинди фәнни аңлатма бармы?**

– Практика күрсәтүенчә, кешеләр язын гына түгел, ел әйләнәсе гашыйк була. Яз – йокыдан уяну, яшәрү, яңару чоры, бәлки, бу чорда еш гашыйк булу шуның белән дә бәйледер. Шуңа күрә язны гашыйк булу белән бәйләп карарга күнеккәнбез.

***– Хисләр һәрвакытта да җаваплы булмый... Җавапсызын да мәхәббәт дип атый алабызмы?***

– Алабыз, әлбәттә. Мәхәббәтнең төрле стадияләре бар: симпатия, гыйшык, ярату. Җавапсыз хисләр дә – мәхәббәт.

**– Ул җавапсыз булганда нишләргә соң?**

– Хисләренне белдерәп торган ниндидер адым ясарга кирәк. Мәхәббәт хисе нинди генә булса да – җаваплымы ул, җавапсызмы – кешегә



нәрсә дә булса бирә дип саныйм. Әлеге сихри утта янган кешенең мотивациясе була, ул сайлаган кешесенең дә шундый хисләр кичерүен тели, үзенә гашыйк булуын көтә. Тик күпчелек очракта бу чын мәхәббәт булмаска да мөмкин. Гашыйк булгандa, кеше партнерының нинди икәнен күреп бетерми, ул үз хисләре белән генә яши, ә партнерын ничек бар шулай итеп кабул итәргә әзер түгел. Чын мәхәббәт бары партнерның хисләрен дә ихтирам итә башлагач кына була. Ул сине яратмаска да мөмкин, һәм син аның бу теләген, фикерен хөрмәт итәргә тиешсең. Тормыш тәҗрибәсе булган кешеләр моны аңлый, ә яшьләр максималист була, шуңа күрә партнердан да күпне таләп итә. Һәм, хисләренә җавап бирмәсәләр, төрле гамәлләргә барырга мөмкин.

***– Хәтта элмәккә мену очраклары да билгеле...***

– Әйе, мондый очраклар бар. Минемчә, суицид – соңгы чик. Җавапсыз хисләр белән көрәшүнең күп кенә башка ысуллары да бар бит. Суицид темасы ул гомумән катлаулы. Яшь кешенең тормышы белән хушлашуы төрле факторларга нигезләнергә мөмкин, моны һәрвакытта да җавапсыз мәхәббәткә генә сылтап калдыру дөрес булмас. Белгечләр тарафыннан әйтелә торган бер фикер бар: кешеләрнең күпчелеге тормышының теге яки бу этабында суицид турында уйланып алырга мөмкин.

Әлерәк кенә студентларга стресс халәте психологиясе курсы буенча лекцияләр сөйләдем. Узган ел булган бер очракны мисал итеп китердем. Бер егет асылынган һәм аны коткарганнар иде. Вакыйгадан соң аның белән сөйләштек, бауга менәргә китергән сәбәпләрне ачыкларга тырыштык. Аңа 17 яшь иде. Ул, машинада барганда, йөргән кызын икенче бер егет белән күргән. Шул ук көнне кызган баштан бауга да менгән. Урамдагы реклама щитына асылынган. Кызы янында барган егетнең кем булуын да ачыклап тормаган. Сөйләшә торгач, аның балачагы авыр булганлыгы ачыкланды. Әтисе Грузиядән, әнисе Болгариядән, алар Казанда очрашып өйләнешкәннәр, тик, малай кечкенә вакытта, аны әнисе ташлап киткән. Соңыннан аны әтисе дә ташлаган, малай әтисе ягыннан бабасы тәрбиясендә үскән. Аннары яңадан Казанга балалар йортына килеп эләккән һәм, 12 яшьләр булганда, малайны уллыкка алганнар. Җитеш гаиләгә эләккән, 17 яше тулар-тулмас машина да алып биргәннәр. Шуларны белгәч, кызын башка егет белән күрүне ни өчен авыр кичерүен аңладык. Егетебез кызның да шәхес булуын, үз фикере булып, үзен теләгәнчә тота алуын кабул итә алмаган. Минеке дип кенә караган. Шуңа күрә һәр конкрет вакыйгага аерым якын килеп карарга кирәк. Балалар үз-үзләренә кул салуга барып җитмәсен өчен, гаилә дә, дәүләт тә ниндидер чаралар күрергә тиеш.

**– Суицидка барып җиткән яшьләр арасында кызлар күбрәкме, әллә егетләрме?**

– Гомумән алганда, суицидка ешрак кызлар тартыла. Ә тәгаенләнгән суицидлар ирләр арасында ешрак.

**– Җавапсыз мәрәҗәгать итәргә сәбәп була аламы?**

– Минемчә, җавапсыз хис кичергән саен, психологка барырга кирәкми. Бу – нормаль күренеш, ул күпләрдә булырга мөмкин. Әгәр инде яшүсмер чын мәгънәсендә төшенкелеккә бирелә, үз алдына яшәргә-юкмы дигән сорау куя башлый икән, бу очракта психологка гына түгел, психиатрга ук күренергә кирәк.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Битка салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәширият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 ны танылык белән теркәлде.
Бастырылыга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.